МИНИСТЕРСТВО ЗЕМЕЛЬНЫХ И ИМУЩЕСТВЕННЫХ ОТНОШЕНИЙ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.02.2020 Казан ш. № 89-пр

**Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында**

1. Тәкъдим ителгән Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын расларга.

2. Министр урынбасарларына, идарә башлыкларына хезмәткәрләрне әлеге боерык белән расланган Регламент белән таныштыруны оештырырга һәм аның тайпылышсыз үтәлешен тәэмин итәргә.

3. Түбәндәгеләрне көчен югалткан дип танырга:

«Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 13.02.2017 ел, № 283-р карарын;

«Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 13.02.2017 № 283-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 31.05.2018 № 1500-р карарын;

«Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 13.02.2017 № 283-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 22.03.2019 № 111-пр боерыгын;

«Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 13.02.2017 № 283-р карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 28.05.2019 № 244-пр боерыгын.

4. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны министрның беренче урынбасары А.И. Галиевка йөкләргә.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
18.02.2020 № 89-пр
карары белән расланды

# Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Регламент Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартларын һәм тәртибен билгели.

1.2. Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү (алга таба - яңадан бүлү турында килешү) Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) нигезендә түбәндәге очракларда төзелә:

1) андый җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен төзелеп беткән территориянең үсеше турында килешү төзелгән әлеге территориянең чикләрендә яңадан бүлү шул җир кишәрлекләре чикләрен территорияне ызанлауның расланган проектына туры китерү максатыннан гамәлгә ашырыла;

2) җир кишәрлекләре чикләрен территорияне ызанлауның расланган проектына туры китерү максатыннан андый җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен чикләрнең чөйләнүен, бөрчекләнүен, сынуын, басу ашалыкны булдырмау өчен яңадан бүлү шәхси милектәге җир кишәрлекләренең мәйданы әлеге яңадан бүлү нәтиҗәсендә җир кишәрлекләренең билгеләнгән максималь үлчәмнәреннән артмау шартларында гамәлгә ашырыла;

3) Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм гражданнар милкендә булган шәхси ярдәмче хуҗалык, яшелчәчелек, бакчачылык, дача хуҗалыгы, индивидуаль торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләрен гражданнар милкендә булган җир

кишәрлекләре мәйданы әлеге яңадан бүлү нәтиҗәсендә җир кишәрлекләренең билгеләнгән максималь үлчәмнәреннән артмау шартларында гамәлгә ашырыла;

4) җир кишәрлекләре Россия Федерациясе Җир кодексының 49 статьясында каралган капиталь төзелеш объектларын урнаштыру өчен, шул исәптән, дәүләти яки муниципаль ихтыяҗлар өчен җир кишәрлекләрен тартып алу максатларында ясала.

1.3. Гариза бирүчеләр - Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен, милек хокукында физик һәм юридик затлар ия булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү белән кызыксынган һәм җир кишәрлегенең милек хуҗасы булган физик һәм юридик затлар.

Гариза бирүче исеменнән тиешле тәртиптә рәсмиләштерелгән ышанычнамә нигезендә вәкаләтләр бирелгән зат эш йөртә.

1.4. Дәүләт хезмәте Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында (алга таба – Министрлык) күрсәтелә.

1.4.1. Министрлыкның урнашу урыны: Казан ш., Вишневский ур., 26 й.

Министрлыкның эш графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, дүшәмбе – пәнҗешәмбе – 9.00дән 18.00гә кадәр, җомга – 9.00дән 16.45кә кадәр, төшке аш 11.45тән 12.30га кадәр. Гаризалар кабул итү графигы: шимбә һәм якшәмбедән кала көн саен, Министрлыкның эш сәгатьләрендә.

Җәмәгать транспортында:

№ 1, 4, 25, 43, 71 номерлы автобуслар белән «Калинин» тукталышына кадәр барырга;

метро станциясе – «Сукно бистәсе».

1.4.2. Министрлыкның Җир ресурслары идарәсенең дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлегенең (алга таба – Бүлек) белешмә телефоннары: 221-40-39, 221-40-89.

1.4.3. Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайты адресы: http://mzio.tatarstan.ru.

1.4.4. Дәүләт хезмәте турында мәгълүматны түбәндәгечә алып була:

1) Министрлыкның гариза бирүчеләр белән эшләү өчен билгеләнгән бүлмәләренә урнаштырылган дәүләт хезмәте турында визуаль һәм текст рәвешендәге мәгълүматны эченә алган мәгълүмат стендларыннан;

2) «Интернет» челтәре ярдәмендә:

Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайтыннан (алга таба – рәсми сайт) (http://mzio.tatarstan.ru);

Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru);

3) Министрлыкка телдән мөрәҗәгать итеп (шәхсән яки телефоннан);

4) Министрлыкка язмача (шул исәптән электрон документ рәвешендә) мөрәҗәгать итеп.

5) дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүче күпфункцияле үзәкләргә мөрәҗәгать итеп.

1.4.5. Министрлыкның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш графигы, рәсми сайт адресы турында мәгълүмат, шулай ук, электрон почтасы турындагы мәгълүмат Бүлек белгече тарафыннан «Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмати системасындагы Министрлык рәсми сайтына һәм Татарстан Республики дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталына урнаштырыла.

Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә бирелгән мәгълүмати стендлардагы мәгълүмат әлеге Регламентның 1.3.1, 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.11, 5.1 пунктлардагы (подпунктта) дәүләт хезмәте турындагы белешмәне үз эченә ала.

1.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәгеләр нигезендә хәл ителә:

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2001, № 44, 4147 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

Россия Федерациясе Салым кодексы (алга таба – РФ Салым кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 1998, № 31, 32, 3824 б., 3340 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Россия Федерациясе Җир кодексын гамәлгә кертү турында» 25.10.2001, № 137-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 137-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 29.10.2001, № 44, 4148 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Кадастр эшчәнлеге турында» 24.07.2007, №221-ФЗ Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2007, №31, 4017 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон (алга таба – № 210-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2010, № 31, 4179 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Электрон имза турында» 06.04.2011 № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2011, №15, 2036 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Күчемсез милекне дәүләт теркәве турында» 13 июль 2015 ел № 218-ФЗ Федераль закон (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru) 2015, 14 июля, бастырылган номеры 0001201507140007,

кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) (алга таба - «Көчемсез милекне дәүләт теркәве турында» Федераль закон);

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы (алга таба – РФ Президенты Указы № 601) (Россия Федерациясе законнары җыелмасы, 2012, № 19, 2338 б.);

«Территориянең кадастр планында җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре урнашу схемасын раслау турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген сату буенча аукцион үткәрү яисә дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлегенә аренда килешүе төзү хокукына аукцион үткәрү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында алдан килешү турында, дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген бирү турында гариза бирү ысулларын һәм тәртибен раслау турында һәм дәүләт яки муниципаль милектәге җир кишәрлеген, шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрен кулланып гариза бирү, шулай ук аларның форматларына куелган таләпләр турында» 14.01.2015, № 7 Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгы боерыгы (алга таба – Боерык № 7) (Хокукый мәгълүмат рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 27.02.2015, бастырылу номеры: 0001201502270011);

Татарстан Республикасы Җир кодексы (алга таба – ТР ҖК) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1998, 15 август, кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы мәсьәләләре» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәсе (алга таба – Нигезләмә) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 03.10.2007, № 37, 1379 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 08.12.2010, № 46, 2144 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында» 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 675 ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 39, 1928 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе турында» 07.08.2012, № 674, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары дәүләт хезмәте күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати үзара бәйләнеше тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары, башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, №59, 2041 б., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

«Татарстан Республикасы милкендә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән бергә яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир кишәрлекләренең мәйданы артканы өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 19.03.2015 № 168 карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендә булган яисә дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре белән бергә яңадан бүлү нәтиҗәсендә шәхси милектә булган җир кишәрлекләренең мәйданы артканы өчен түләү күләмен билгеләү тәртибе («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм башкарма хакимиятнең республика органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2015, № 25, 0857 б. кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып).

1.6. Әлеге Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр кулланыла:

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәге (күпфункцияле үзәк, МФЦ) – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль закон таләпләренә җавап бирә һәм «бер тәрәзә» принцибында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне, шул исәптән электрон формада да, оештыруда вәкаләтле, дәүләти яки муниципаль учреждениенең оештыру-хокукый формасында төзелгән оешма (шул ук вакытта автоном учреждение булып тора);

дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районнардагы (шәһәр округында) шәһәр һәм авыл җирлекләрендә «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);

«бер тәрәзә» принцибы – гариза бирүченең дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү турында яки «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән запрос белән мөрәҗәгатеннән соң аңа дәүләти яки муниципаль хезмәт күрсәтү принцибы, дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнар белән, муниципаль хезмәтләре күрсәтүче органнар белән арадашлыкны күпфункцияле үзәк норматив хокукый актлар һәм аралашлык турында килешүләр нигезендә гариза бирүченең катнашыннан башка үзе башкара;

техник хата – документларга кертелгән белешмәләрнең (дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе) алар нигезләнгән документлардагы мәгълүмат белән туры килмәвенә китергән Министрлык җибәргән хата (язудагы хата, ялгыш басылу, грамматик яки арифметик хата);

дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - № 210-ФЗ Федераль законның 2 статьясындагы 1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.

## 2. Стандарт предоставления государственной услуги

| Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы | Стандартка таләпләр эчтәлеге | Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт |
|---|---|---|
| 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы | Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү | РФ ЖК $39^{28}$ – $39^{29}$ ст.;<br>ТР ЖК 4 ст.;<br>Нигезләмә 3.3.4 п. |
| 2.2. Башкарма хакимият органы атамасы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы (алга таба – Министрлык) | Нигезләмә |
| 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы | Җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карар кабул итү һәм карарны схемасы белән бергә гариза бирүчегә җибәрү;<br>гариза бирүчегә территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык җибәрү;<br>гариза бирүчегә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү җибәрү<br>җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү | РФ ЖК 39.29 ст. 8 п. ;<br>Нигезләмә 3.3.4 п. |
| 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү срогы, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү | Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать кергәннән соң 17 эш көне эчендә күрсәтелә.<br>Җир кишәрлеге ясалырга тиешле җир | РФ ЖК $39^{29}$ ст. 8, $8^{1}$ п. |

| | | |
|---|---|---|
| зарурлыгын да исәпкә алып, Россия Федерациясе законнарында каралган очракта дәүләт хезмәте күрсәтүне туктату срогы, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган документларны бирү (җибәрү) срогы | кишәрлегенең урнашу схемасына № 137-ФЗ Федераль законның 3.5 статьясы нигезендә килештерү таләп ителсә, бу срок Регламентның әлеге пунктының беренче абзацында каралганча, җир кишәрлекләрен яңача бүлү турында гариза кергәннән соң 45 көнгә кадәр озайтыла.<br>Дәүләт хезмтен күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә. | |
| 2.5. Дәүләт хезмәте, шулай ук гариза бирүчегә күрсәтелергә тиешле дәүләт хезмәтләрен күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләрне күрсәтү өчен закон яки башка норматив-хокукый актлар нигезендә кирәкле документларның тулы исемлеге, гариза бирүченең аны алу ысуллары, аларны бирү тәртибе, шул исәптән, электрон формада һәм аны тапшыру тәртибе | Җир кишәрлеген яңадан бүлү турында гаризага түбәндәгеләр беркетелә:<br>1) милек хокукы Күчемсез милек бердәм реестрында регистрацияләнмәгән очракта гариза бирүченеке булган җир кишәрлегенең хокукын билгели яки хокукын раслый торган документларның күчермәсе;<br>2) чикләрендә җир кишәрлекләре яңадан бүленә торган территориянең ызанлау проекты булмаган очракта җир кишәрлегенең урнашу схемасы;<br>3) җир кишәрлеген бирү турында гариза | РФ ЖК $39^{29}$ ст. 2, 2 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта гариза бирүче вәкиленең вәкаләтләрен раслаучы документ;<br>4) гариза бирүче чит ил юридик заты булган очракта, юридик затның чит дәүләт законнарына туры китереп дәүләт регистрациясен үтүе турында рус телендә расланган тәрҗемәсе.<br>Гаризага беркетлә торган документларның күчермәләре нотариус яки документның төп нөсхәсен биргән орган (оешма, учреждение) тарафыннан расланмаган булса, күчермәләрне Министрлык белгече расласын өчен төп нөсхәсе дә тәкъдим ителә.<br>Яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килә торган җир кишәрлегенең кадастр паспорты/Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРНнан өземтә).<br>Гариза һәм аңа беркетелгән документлар гариза бирүче тарафыннан кәгазьгә бастырылып түбәндәге ысуллар белән тапшырыла (җибәрелә) ала:<br>шәхсән (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче тарафыннан);<br>почта аша.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати- | $39^{29}$ ст. 13 п.;<br>Федераль закон № 218-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | телекоммуникацион челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон документлар рәвешендә бирү өчен мәҗбүри шарт булып аларны электрон имза белән, 6 апрель 2011 ел № 63-ФЗ Федераль закон һәм 27 июль 2010 ел № 210-ФЗ Федераль законга туры китереп имзалау тора. | |
| 2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма | Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:<br>1. Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан гариза бирүче булган юридик зат турында белешмә (алга таба – ЕГРЮЛ) - Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә (алга таба – ТР буенча ФСХИ);<br>2. Гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында Шәхси эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан (алга таба – ЕГРИП) белешмә - ТР буенча ФСХИга;<br>3. Җир кишәрлеге турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН) яки ЕГРНда җир кишәрлеге турында мәгълүмат булмавы турында белдерү кәгазе - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр). | РФ ЖК $39^{29}$ ст.;<br>Федераль закон № 218-ФЗ |

| | | |
|---|---|---|
| | Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлек булган очракта электрон формада да.<br>Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән белешмәләр булган документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тартуга сәбәп булып тормый.<br>Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.<br>Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:<br>Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне, гамәлләр башкару таләп итү;<br>Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен | РФ ҖК $39^{29}$ ст. 4 п. |

| | | |
|---|---|---|
| | түләү кертелүен раслаган докуемнтларны сорау. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар искәрмә булып тора;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә 4 пунктында күрсәтелгән очраклар чыгарылма булып тора. | |
| 2.7. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тартуга нигезләрнең тулы исемлеге | 1. Гариза РФ ҖК $39^{29}$ статьясының 2 пункты таләпләренә туры килми;<br>2. Гариза башка вәкаләтле органга тапшырылган;<br>3. Гаризага әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелмәгән;<br>4. Гаризада һәм аңа беркетелгән документларда тиешле тәртиптә расланмаган чистартылган, өстәп язылган һәм төзәтелгән урыннар булуы;<br>5. Министрлыкка гаризаны һәм башка документларны (документларның күчермәләрен) № 7 Боерык таләпләренә туры килмәгән электрон форматта, 2011 елның 6 апреле, № 63-ФЗ Федераль закон һәм 2010 елның 27 июле, № 210-ФЗ Федераль | РФ ҖК $39^{29}$ ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | закон таләпләре нигезендә электрон имза куймыйча тапшыру. | |
| 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Законнарда дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр каралмаган. | РФ ҖК $39^{29}$ ст. |
| 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткән өчен алына торган дәүләт пошлинасы яки башка төрле түләүнең тәртибе, күләме һәм алу нигезләре | Дәүләт хезмәте түләүсез күрсәтелә | |
| 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан оешмалар биргән документ (документлар) турында белешмә | Мәҗбүри һәм зарури хезмзтләр күрсәтү таләп ителми | |
| 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы алынучы түләүләрнең тәртибе, күләме һәм нигезләре, андый түләү күләмен исәпләү методикасы турындагы мәгълүматны да кертеп | Яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеген дәүләт кадастр исәбенә алу максатыннан РФ ҖК $39^{29}$ ЗК РФ статьясының 11 пунктында каралган кадастр эшләрен үткәрү законнарда билгеләнгән күләмдә гариза бирүче (җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар кабул итүгә китергән гаризаны бирүче зат яки территорияне ызанлауның расланган | РФ ҖК $39^{29}$ ст., 11 п.,<br>ТР МК Карары № 675,<br>РФ Салым Кодексының $333^{33}$ ст. |

| | | |
|---|---|---|
| | планы нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык юлланган зат) хисабына үткәрелә | |
| 2.12. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы оешмага дәүләт хезмәте күрсәтү турында запрос биргәндә һәм андый хезмәтләрне күрсәтүнең нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь срогы | Гариза бирүченең кабул итүне (хезмәт күрсәтүне) көтүенең һәм дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсен алуның максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.<br>Гариза бирүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән. | РФ Президенты Указы № 601, 1 п. |
| 2.13. Дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап гариза бирүченең запросын, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы оешманың хезмәтен регистрацияләү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада | Гариза һәм документлар кергән бер көн эчендә.<br>Ял (бәйрәм) көнендә электрон формада кергән гариза ял (бәйрәм) көненнән соң килгән эш көнендә регистрацияләнә. | |
| 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләргә, мөрәҗәгать итүчеләрнең көтеп тору урыннарына, дәүләт хезмәте күрсәтү турында запросларны тутыру урынына, аларны тутыру үрнәкләре һәр дәүләт хезмәтен күрсәтү өчне зарури документлар исемлеге урнаштырылган мәгълүмати стендларның урныштырылуына һәм әлеге хезмәт | Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазы булган, мәгълүмати стенд һәм Татарстан Республикасы дәүләт телекоммуникацияләренең берләштерелгән системасына тоташтыфрылган мәгълүмат икиоск куелган бүлмәләрдә башкарыла.<br>Инвалидларга каршылыксыз керә алу, шул исәптән каршылыксыз кереп чыгу мөмкинлеге | |

| | | |
|---|---|---|
| күрсәтелү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиалы мәгълүматка, шул исәптән, Россия Федерациясенең инвалидларны социаль яклау турында законнарына туры китереп әлеге объектларның инвалидлар керә алырлык булуын тәэмин итүгә карата таләпләр | белән тәэмин ителә, шул исәптән тиешле урынга килеп җитә алу максатында объект буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү мөмкинлеге тудырыла.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла. | |
| 2.15. Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булуы һәм сыйфаты күрсәткечләре, шул исәптән, гариза бирүченең дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә вазыйфаи затлар белән үзара бәйләнеше саны һәм вакыт озынлыгы, дәүләт хезмәте күрсәтелү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән, мәгълүмати-коммуникацион технологияләрне кулланып, дәүләт хезмәтен дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәгендә (шул исәптән, тулы күләмдә), башкарма хакимият органының гариза бирүче сайлаган теләсә кайсы территориаль бүлекчәсенә (экстерриториаль принцип) дәүләти һәм | Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;<br>Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү;<br>инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка барьерларны үтәргә булышу;<br>кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;<br>мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында | |

| | | |
|---|---|---|
| (яки) муниципаль хезмәтләр күрсәтү турында дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күпфункцияле үзәкләренә №210-ФЗ Федераль законның 15[1] статьясы нигезендә запрос биреп алып булу яки булмау мөмкинлеге | дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы.<br>Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:<br>документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;<br>дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;<br>Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;<br>Гариза бирүченең министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;<br>дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел.<br>дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.<br>Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү дә, күпфункцияле үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү | |

| | | |
|---|---|---|
| | күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.<br>Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша алырга мөмкин. | |
| 2.16. Башка таләпләр, шул исәптән, дәүләт хезмәтен экстерриториаль принцип буенча күрсәтү үзенчәлекләрен истә тотып (дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча күрсәтелгән очракта) һәм дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү үзенчәлекләре | Консультация алу өчен гариза бирүче шәхсән үзе, телефон аша һәм (яки) электрон почта, почта аша Бүлеккә мөрәҗәгать итә ала.<br>Дәүләт хезмәте электрон формада, шул исәптән, «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын файдаланып, күрсәтелми.<br>Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора. | Федераль закон № 63-ФЗ;<br>Федераль закон № 210-ФЗ<br>РФ ЖК $39^{29}$ ст.;<br>Боерык № 7 |

## 3. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм үтәлү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларның (гамәлләрнең) электрон рәвештә үтәлүе үзенчәлекләре

3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдә гамәлләр эзлеклелегенең тасвирламасы

3.1.1. Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар тутыру буенча да;

гаризаны кабул итү һәм регистрацияләү;

дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар формалаштыру һәм юллау;

җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карар әзерләү һәм кабул итү яки территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалыкны юллау, яисә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү;

Министрлыкка тапшырылган яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлегенең кадастр паспортын/ЕГРНнан өземтән карап чыгу;

җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү.

гариза бирүчегә баш тарту турында карарны яки җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карарны, яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны тапшыру;

җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү әзерләү яисә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар әзерләү;

гариза бирүчегә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүне, яисә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карарын тапшыру;

дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып;

дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсе булган документларда киткән ялгышларны һәм хаталарны төзәтү.

3.2. Гариза бирүчегә консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм итү, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Гариза бирүче, дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен, Бүлеккә шәхсән, телефоннан, һәм (яки) электрон почта аша мөрәҗәгать итүгә хокуклы.

Бүлек белгече гариза бирүчегә, аның нинди ысул белән мөрәҗәгать итүенә карап, шәхсән үзенә, телефоннан, электрон почта аша һәм (яки) хат белән консультация бирә, шул исәптән тапшырылырга тиешле документларның составы, формасы ягыннан һәм дәүләт хезмәте алуга карата башка мәсьәләләр буенча, гариза бирүчегә ярдәм итә, шул исәптән, дәүләт хезмәте тутыру өчен кирәкле документлар тутыру буенча да.

Әлеге пункт билгели торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне (гариза теркәлгән көн) үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: консультация, гариза бирүчегә күрсәтелгән ярдәм, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен кирәкле документларны тутырырга булышу.

3.3. Гаризаны кабул итү һәм регистрацияләү.

3.3.1. Гариза бирүче әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар беркетелгән гаризасын Министрлыкка бирә.

Гариза һәм документларның нотариус яки документның оригиналын биргән орган (оешма, учреждение) таныклаган күчермәсе почта аша җибәрелә ала.

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булса, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып, электрон документлар форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора.

3.3.2. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

гаризаны һәм документларны кабул итә;

гаризаны һәм документларны кабул итмәү өчен әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигез булу-булмавын тикшерә. Тикшерү Бүлек белгече катнашында башкарыла;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигез булмаган очракта гаризаны һәм беркетелгән документларны теркәп, карау өчен Бүлеккә юллый;

әлеге Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән нигезләр булган очракта

документларны теркәмичә генә, Бүлек белгече әзерләгән, документларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләре күрсәтелгән аңлатма белән бергә, гариза бирүчегә кайтара.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза һәм документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла, гариза һәм документларның электрон формада ял көне (бәйрәм көнне) тапшырылуы чыгарылма булып тора.

Процедураларның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм Бүлеккә юлланган гариза; гариза бирүчегә кайтарылган документлар.

3.4. Ведомствоара запрослар формалаштыру һәм дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашкан органнарга юллау

3.4.1. Бүлек белгече Эш башкару бүлегеннән гаризаны һәм документларны алгач “Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гаризаның ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында үтү бите”н тутыра (3нче кушымта) һәм ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша электрон формада түбәндәге запросланы юллый:

гариза бирүче булган оешма - юридик зат турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

гариза бирүче булган шәхси эшмәкәр турында белешмә бирү турында, ТР буенча ФСХИдан;

җир кишәрлегенә турында ЕГРНнан өземтә яки җир кишәрлеге турында ЕГРНда соралган белешмә булмавы турында белдерү - ТР буенча Росреестрдан.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедурадан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: белешмә (документлар) бирү турында запрослар.

3.4.2. Ведомостводара арадашлык органнары белгечләре әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән, ведомствоара электрон арадашлык системасы аша кергән запрослар нигезендә билгеләнгән срокта соралган документларны (белешмәләрне) бирәләр.

Процедура нәтиҗәсе: запросларга җавап нәтиҗәсе булган белешмәләр (документлар), яисә Министрлыкка юлланган соралган белешмәләрнең булмавы турында белдерү.

3.4.3. Бүлек белгече № 137-ФЗ Федераль законның $3^5$ статьясы нигезендә, № 137-ФЗ Федераль законның $3^5$ статьясының 10 пунктында күрсәтелгән җирләрдән җир кишәрлеге ясау очракларыннан тыш, гариза бирүче тапшырган җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына запрос юллый һәм гариза бирүчегә җир

кишәрлеген урнашу схемасын килештерүгә җибәрү турында белдерелүен тәэмин итә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар җир кишәрлеген яңадан бүлү турында гариза һәм аңа беркетелгән документлар Бүлеккә кергәннән соң ике эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүче тапшырган җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү турында юлланган запрос, җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерүгә юллау турында гариза бирүчегә хәбәр итү.

3.4.4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белгечләре 3.4.3. пунктта күрсәтелгән запрос нигезендә законнарда билгеләнгән срокларда җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү турында яисә килештерүдән баш тарту турында белдерү бирәләр

Процедура нәтиҗәсе: запроска җавап буларак Министрлыкка юлланган җир кишәрлеге урнашу схемасын килештерү турында яисә килештерүдән баш тарту турында белдерү.

3.5. Җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында карар әзерләү һәм кабул итү яки территорияне ызанлауның расланган проекты нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалыкны юллау, яисә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул итү

3.5.1. Бүлек белгече әлеге Регламентның 3.4.1 пунктында күрсәтелгән белешмәләр (документлар) килгәч, шулай ук, әлеге Регламентның 3.4.3 пункты нигезендә гариза бирүче тапшырган җир кишәрлеге урнашу схемасын җибәргән очракта Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгыннан белдерү килгәч, түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарта торган нигезләрнең булу-булмавын тикшерә. Әлеге Регламентның 4 кушымтасында күрсәтелгән нигезләрнең берсе генә булса да, Бүлек белгече җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар әзерли;

андый нигезләр булган очракта җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карары проектын (алга таба – баш тарту турында карар проектын) яки чикләрендә җир кишәрлекләрен яңадан бүленә торган территорияне ызанлау проекты булмаган очракта, җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карары проектын (схеманы раслау турында карар проектын) яисә территорияне ызанлауның

расланган проекты нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык турында хат проектын (алга таба - килешү төзүгә ризалык турында хат проектын) әзерләү;

баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллау.

Әлеге пункт билгели торган процедура юлланган запросларга җавап алынганнан соң ике эш көне эчендә үтәлә.

Процедура нәтиҗәсе: әзерләнгән һәм килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.2. Бүлек мөдире баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын карап чыга, килештерә һәм килештерү өчен Җир ресурслары идарәсе (алга таба – Идарә) башлыгына юллый.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире белән килештерелгән һәм килештерү өчен Идарә башлыгына юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.3. Идарә башлыгы баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын карап чыга, килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

3.5.2, 3.5.3 пунктлар белән билгеләнә торган процедуралар, аннан алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм Бүлек белгеченә юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.4. Бүлек белгече Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын хокук идарәсенә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура Министрлык карарын Идарә башлыгы килештергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире һәм Идарә башлыгы белән килештерелгән һәм хокук идарәсенә юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.5. Хокук идарәсе белгече баш тарту турында карар проектына яки схеманы раслау турында карар проектына яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектына хокукый экспертиза ясый, килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына килештерелгән баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны яисә хокук идарәсе бәяләмәсе проектын (кимчелекләр булган очракта) юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура, аннан алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юлланган хокук идарәсе бәяләмәсе проекты (кимчелекләр булган очракта) яки килештерелгән баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.6. Хокук идарәсе башлыгы баш тарту турында карар проектына яки схеманы раслау турында карар проектына яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектына хокук идарәсе бәяләмәсен имзалый яки баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын килештерә һәм Бүлек белгеченә юллый.

Әлеге пункт билгели торган процедура, аннан алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: баш тарту турында карар проектына яки схеманы раслау турында карар проектына яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектына хокук идарәсе бәяләмәсе яки килештерелгән баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.7. Бүлек белгече хокук идарәсе бәяләмәсен алган очракта булган кимчелекләрне төзәтә һәм баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын килештерү өчен хокук идарәсе башлыгына юллый.

3.5.8. Хокук идарәсе башлыгына хокук идарәсе бәяләмәсендә күрсәтелгән кимчелекләрнең төзәтелүен тикшереп чыга һәм баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын килештерә.

3.5.7 һәм 3.5.8 пунктлар билгеләгән процедуралар алдагы процедура беткәннән соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән һәм бүлек белгеченә юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.9. Бүлек белгече хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән баш тарту турында карар проектын яки схеманы раслау турында карар проектын яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проектын имзалау өчен министрның беренче урынбасарына юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: Бүлек мөдире, Идарә башлыгы, Хокук идарәсе башлыгы белән килештерелгән һәм министрның беренче урынбасарына юлланган баш тарту турында карар проекты яки схеманы раслау турында карар проекты яисә килешү төзүгә ризалык турында хат проекты.

3.5.10. Министрның беренче урынбасары баш тарту турында карарны яки схеманы раслау турында карарны яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны имзалый һәм регистрация өчен эш башкару һәм контроль бүлегенә юллый.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: министрның беренче урынбасары имзалаган һәм регистрация өчен эш башкару һәм контроль бүлегенә юлланган баш тарту турында карар яки схеманы раслау турында карар яисә килешү төзүгә ризалык турында хат.

3.6. Гариза бирүчегә баш тарту турында карарны яки схеманы раслау турында карарны яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны тапшыру

3.6.1. Эш башкару һәм контроль бүлеге белгече баш тарту турында карарны яки схеманы раслау турында карарны яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны регистрацияли, баш тарту турында карар яки схеманы раслау турында карар кабул ителгәннән яисә килешү төзүгә ризалык турында хат имзаланганнан соң өч көн эчендә гариза бирүче күрсәткән почта адресы белән җибәрә. Баш тарту турында карарның яки схеманы раслау турында карарның яисә килешү төзүгә ризалык турында хатның күчермәсен эш башкару бүлеге белгече Бүлеккә юллый.

Гариза бирүченең теләге буенча Бүлек белгече телефон аша баш тарту турында карарны яки схеманы раслау турында карарны яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны бирү өчен билгеләнгән вакытны хәбәр итә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура беткәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: эш башкару бүлегендә регистрацияләнгән баш тарту турында карар яки схеманы раслау турында карар яисә килешү төзүгә ризалык турында хат, документларның Бүлеккә юлланган күчермәләре.

3.6.2. Гариза бирүче баш тарту турында карар яки схеманы раслау турында карар яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны алырга килгәч, эш башкару бүлегенең документларны тапшыру өчен җаваплы белгече түбәндәгеләрне башкара:

гариза бирүченең шәхесен ачыклый, шул исәптән шәхесен раслаучы документны тикшерә; вәкилнең вәкаләтләрен (боерык, ышанычнамә һ.б.) тикшерә;

баш тарту турында карарны яки схеманы раслау турында карарны яисә килешү төзүгә ризалык турында хатны тапшыра һәм исәп-хисап кенәгәсенә докуиентлар тапшырылуы турында язып куя.

Әлеге пункт билгеләгән процедура алдагы процедура гариза бирүче килгән көнне тормышка ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә тапшырылган баш тарту турында карар яки схеманы раслау турында карар яисә килешү төзүгә ризалык турында хат.

3.7. Министрлыкка тапшырылган яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлегенең кадастр паспортын/ЕГРНнан өземтәне карап чыгу

3.7.1. Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында карар кабул итүгә китергән гаризаны бирүче зат яки территорияне ызанлауның расланган планы нигезендә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүгә ризалык юлланган зат яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлекләрен дәүләт кадастр исәбенә алу максатыннан кадастр эшләрен үткәрүне тәэмин итә һәм андый җирләргә дәүләт кадастр исәбе үткәрү турында гариза белән мөрәҗәгать итә.

3.7.2. Гариза бирүче яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләре дәүләт кадастр исәбенә алынганнан соң Министрлыкка яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләренең кадастр паспортын/ЕГРНнан өземтәне тапшыра.

3.8. Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү

3.8.1. Бүлек хезмәткәре Министрлыкка яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләренең кадастр паспорты/ЕГРНнан өземтә кергәннән соң җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проекты әзерли.

Җир кишәрлеге урнашу схемасында яки территорияне ызанлауның проектында күрсәтелгән җир кишәрлеге нигезендә ясалган һәм хосусый милек хокукы барлыкка килгән җир кишәрлегенең мәйданы алдагысыннан ун

проценттан күбрәккә артык булган очракта, Бүлек хезмәткәре җир кишәрлекләрен бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карары проекты әзерли.

3.8.2. Әзерләнгән җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү проекты яки җир кишәрлекләрен бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карары проекты әлеге Регламентның 3.5.1. – 3.5.10 п.ларында билгеләнгән тәртиптә министрның беренче урынбасарына юллана.

3.8.3. Гариза бирүчегә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүне яки җир кишәрлекләрен бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карарын тапшыру әлеге Регламентның 3.6.1 – 3.6.2 пунктларында билгеләнгән тәртиптә башкарыла.

3.8.1 – 3.8.3 пунктлар белән билгеләнгән процедуралар Министрлыкка яңадан бүлү нәтиҗәсендә барлыкка килгән җир кишәрлеге яки җир кишәрлекләренең кадастр паспорты/ЕГРНнан өземтә тапшырылганнан соң 17 эш көне эчендә башкарыла.

Процедура нәтиҗәсе: җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүнең яки җир кишәрлекләрен бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында Министрлык карарының гариза бирүчегә тапшырылган нөсхәсе.

3.8.4. Гариза бирүче алганнан соң 30 календарь көне эчендә килешүне имзалый һәм имза куелган килешүне Министрлыкка китерә.

3.9. Дәүләт хезмәтен электрон формада күрсәтү тәртибе, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып

Дәүләт хезмәте электрон формада күрсәтелми, шул исәптән, «Татарстан Республикасының дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр порталы» республика дәүләт мәгълүмати системасын кулланып та.

3.10. Дәүләт хезмәте күрсәтелү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны (алга таба – техник хата) төзәтү

Гариза бирүченең җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүдә яки җир кишәрлеге урнашу схемасына раслау турында Министрлык карарында киткән техник хатаны төзәтү буенча мөрәҗәгате Министрлык тарафыннан техник хатаның төзәтелүенә нигез булып тора.

3.10.1. Техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча мөрәҗәгать иткәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (5 нче кушымта);

җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүнең төп нөсхәсе;

җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарының төп нөсхәсе;

техник хатаның барлыгын раслаган документлар.

3.10.2. Җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарында, яки җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүдә техник хатаны төзәтү мәсьәләсе буенча гаризаны гариза бирүче яки аның законлы вәкиле Министрлыкка шәхсән үзе тапшыра яисә почта аша юллый.

3.10.3. Эш башкару бүлеге белгече беркетелгән документлары белән бергә гаризаны кабул итеп ала да, регистрация уздырып, Бүлеккә бирә.

Әлеге пункт билгеләгән процедура гариза һәм документлар китерелгән (кергән) көнне гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: кабул ителгән һәм регистрацияләнгән гаризаның, беркетелгән документлары белән бергә, Бүлек белгеченә карау өчен юллануы.

3.10.4. Бүлек белгече документларны карап чыга һәм җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарына яки җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүгә төзәтмәләр кертү максатыннан (техник хаталарын төзәтү), җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарына яки җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүгә үзгәрешләр проекты әзерли һәм әлеге Регламентның 3.5.1 – 3.5.10, 3.6.1 – 3.6.2 пунктларында каралган тәртиптә күрсәтелгән процедураларны башкара.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедура техник хата табылганнан соң яки теләсә кайсы катнашы булган затның хата турындагы мөрәҗәгатеннән соң өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедура нәтиҗәсе: гариза бирүчегә юлланган җир кишәрлегенең урнашу схемасын раслау турында Министрлык карарына яки җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүгә төзәтмәләр.

3.10.5. Техник хатаны төзәтүгә кагылышлы документлар (беркетелгән документлар белән бергә техник хатаны төзәтү турында мөрәҗәгать, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүгә үзгәрешләр (техник хаталары төзәтелеп) белән бергә җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешүнең Министрлыкта калган нөсхәсе янына беркетелә.

## 4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ процедуралар белән билгеләнгән гамәлләр эзлеклелеге саклануын дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы Идарә (бүлек) җитәкчеләре әлеге Регламент нигезләмәләрен үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән контрольдә тота.

4.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүне Министрлыкның вазыйфаи затлары контрольдә тота. Контрольдә тотучы вазыйфаи затларның вәкаләтләре

Министрлык идарәләре (бүлекләре) турында нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар белән билгеләнә.

4.3. Агымдагы контроль Министрлыкның вазыйфаи затларының әлеге Регламент нигезләмәләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгеләүче башка норматив хокукый актларның үтәвен тикшереп тору юлы белән гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контроль даими нигездә гамәлгә ашырыла.

4.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту тикшерүләр үткәрүне, гариза бирүчеләрнең дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи затларның кылган (кылмаган) гамәлләре турында шикаятьләр булган мөрәҗәгатьләрен карап, карарлар кабул итүне һәм гариза бирүченең мөрәҗәгатенә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

канцелярия эшләрен алып бару;

документлар карау нәтиҗәләренең закон таләпләренә (әлеге Регламентка) туры килүе;

документлар кабул итү срокларын һәм тәртибен саклау;

дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә нәтиҗәләрне тапшыру срогы һәм тәртибе саклану.

Тикшерүләр үткәрү планлы (эш планнары нигезендә гамәлгә ашырыла) һәм планнан тыш (гариза бирүченең мөрәҗәгате буенча) булырга мөмкин.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү буенча планнан тыш тикшерү карары түбәндәге очракларда кабул ителә:

1) әлеге Регламент таләпләрен һәм дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләр билгели торган башка норматив хокукый актларны бозу очраклары алдарак ачыкланып, аларның төзәтелүен тикшерү өчен;

2) Министрлыкның дәүләт хезмәтен күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затларының үз гамәлләре белән (гамәл кылмаулары белән) аларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозулары турында гариза бирүчеләрнең зарланып мөрәҗәгать итү очрагында.

4.6. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен җаваплы вазыйфаи затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла.

4.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту Министрлык эшчәнлегенең дәүләт хезмәте күрсәтүдәге ачыклыгы, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм дәүләт хезмәте күрсәтү барышында

мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карау мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.

## 5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең, шулай ук, аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерү

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата Министрлыкка шикаять белдерә ала.

Министрның дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле карарларына, кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелә.

5.2. Гариза бирүче түбәндәге очракларда да шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең запросын теркәү срогы бозылганда;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү срогы бозылганда;

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган документлар яки мәгълүмат, яки гамәлләр кылуны таләп иткәндә;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясе норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылган документларны кабул итеп алудан баш тартканда;

5) дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартканда, әгәр баш тартуга нигезләр федераль законнар һәм Россия Федерациясенең алар нигезендә кабул ителгән башка норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә күздә тотылмаса;

6) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган түләү таләп иткәндә;

7) Министрлык, Министрлыкның вазыйфаи заты дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартканда яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозганда.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогы яки тәртибе бозылганда;

9) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив-хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив-хокукый актларында күздә тотылмаган булып та, дәүләт хезмәтү күрсәтү туктатып торылса;

10) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән беренче тапкыр кабул иткәндә юклыгы яки дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән, дәүләт хезмәте күрсәткәндә яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны яки мәгълүматны таләп итү, № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясының 1 өлешендәге 4 пункты искәрмә булып тора.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яисә электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, МФЦ аша, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәреннән файдаланып, Министрлыкның рәсми сайты (http://mzio.tatarstan.ru), Татарстан Республикасының Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталы (http://uslugi.tatar.ru), Дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы (http://www.gosuslugi.ru) аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул итү барышында кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять түбәндәге мәгълүматлардан торырга тиеш:

1) карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә шикаять белдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтүче органның атамасы, органның дәүләт хезмәте күрсәтүче вазыйфаи заты яки дәүләт хезмәткәре, аның җитәкчесе һәм (яки) хезмәткәре;

2) гариза бирүче физик затның фамилиясе, исеме, әтисенең исеме (булганда), яшәү урыны турында мәгълүмат, мөрәҗәгать итүче юридик затның атамасы, урнашкан урыны турында мәгълүмат, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (адреслары) (булганда) һәм мөрәҗәгать итүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре турында мәгълүмат;

4) дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт хезмәте күрсәтүче органның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең карары һәм кылган (кылмаган) гамәлләре белән килешмәвенә дәлилләре.

5.5. Шикаятькә анда бәян ителгәннәрне раслый торган документларның күчермәләре беркетелә ала. Бу очракта шикаятькә беркетелгән документлар исемлеге китерелә.

5.6. Шикаять регистрацияләнгәннән соң унбиш көн эчендә карала, ә Министрлыкның гариза бирүчедән документларын кабул итеп алудан баш тартуга яки ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуга яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга карата шикаять белдерелгән очракта - аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә.

5.7. Министрлык шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) шикаятьне канәгатьләндерә, шул исәптән карарны юкка чыгару рәвешендә, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда Министрлык тарафыннан җибәрелгән ялгыш язуларны һәм хаталарны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә түләтү күздә тотылмаган акчаларны  гариза бирүчегә кире кайтарып бирү рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тарта.

5.8. Бу Регламентның 5.7 пунктында күрсәтелгән карар кабул ителгәннән соң килүче көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язмача һәм, гариза бирүченең теләгенә карап, электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында нигезле җавап җибәрелә.

5.9. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип табылса, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә ясалган кимчелекләрне төзәтү өчен Министрлык кылачак гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук килеп туган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм дәүләт хезмәте алу өчен гариза бирүче кылырга тиешле гамәлләр турында мәгълүмат бирелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерелмәсә, бу Регламентның 5.8 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә кабул ителгән карар турында дәлилле аңлатма бирелә, кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе бәян ителә.

5.11. Шикаятьне карау барышында яки аның нәтиҗәләре буенча, административ хокук бозу билгеләре яки җинаять ачыкланса, шикаятьләрне карау вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны тиз арада прокуратура органнарына юллый.

5.12. Министрлыкның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, яисә дәүләт хезмәткәрләренең карарларына һәм кылган (кылмаган) гамәлләренә карата судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә шикаять белдерүгә бәйле мөнәсәбәтләр № 210-ФЗ Федераль закон нигезендә көйләнә.

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына

___________________

(Кемнән) ____________________________________
(ФИӘИ (булса) -физик затлар өчен,
(оештырылу-хокукый формасы - юридик затлар өчен)

_______________________________________________________

(гариза бирүченең (граждан өчен) шәхесен ачыклаган документ реквизитлары)
ИНН белешмәсе______________________________________
ОГРН/ОГРИП белешмәсе_______________________________
урнашкан урыны, , ЕГРЮЛда теркәлүе турында мәгълүмат, ,)
Яшәү урыны (гражданин өчен), урнашкан урыны (юридик зат өчен) ______________________________
Телефн_______________________________________________
Почта адресы һәм (яки) электрон почта адресы_____________

Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында
ГАРИЗА

Татарстан Республикасы милкендәге, түбәндәге адрес белән урнашкан җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүне үтенәм:________________ ______________________________________________________________________________,

мәйданы ___________ кв. м, файдалану максатлары _______________________________,

кадастр номерлары _________________________________________________________,

һәм хосусый милектә булган җир кишәрлекләрен _________________,

урнашкан адресы (урыны): ___________________________________,

мәйданы __________ кв. м, файдалану максатлары ____________________________,

кадастр номерлары ___________________________________________________________

беркетелгән территорияне ызанлау проектына туры китереп (җир кишәрлекләренең яңадан бүленүе әлеге проект нигезендә башкарылуы күздә тотылса, күрсәтелә) _____________________________________________________________________________

яки җир кишәрлегенең расланган урнашу схемасы (чикләрендә җирне яңадан бүлү башкарылачак территорияне ызанлау проекты булмаган очракта күрсәтелә) _________________________________________________

Кушымта:

| N | Документның атамасы |
|---|---|
| 1. | |
| 2. | |
| 3. | |
| 4. | |

“Персональ мәгълүматлар турында” 27.07.2006 ел, №152-ФЗ Федераль законга туры китереп, мин 420043, ТР, Казан ш., Вишневский ур., 26 й. адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына (оператор) персональ мәгълүматны эшкәртергә (әлеге гаризада күрсәтелгән персональ мәгълүматны җыюны, яздыруны, системалаштыруны, туплауны, саклауны, аныклауны (яңарту, үзгәртү), файдалану, тапшыру (тарату, бирү), блоклауны, бетерүне, юкка чыгаруны да кертеп, автоматлаштыру чаралары белән яки алардан башка кылынган гамәл (операция) яисә гамәлләр (операцияләр) белән эшкәртергә рөхсәт бирәм. Мәгълүматның дөреслеген раслыйм.

Әлеге килешү гариза имзаланган көннән башлап язма рәвештә килешүне кире соратып алган көнгә кадәр гамәлдә була.

Гариза бирүченең имзасы (_______№_________________________ышанычнамә буенча вәкил

_______________________________________/_______________________/
(вәкилнең фамилия, имя, әтисе исеме (соңгысы – булганда), имзасы)

М.П. (мөһер булганда)

Гариза кабул ителде: "___"__________ 20__ г.
______/_________________/гаризаны алган Бүлек белгеченең имзасы, фамилиясе, инициаллары)

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында
гаризага беркетелгән документлар
исемлеге

| Документның атамасы һәм реквизитлары | Битләр саны | |
|---|---|---|
| | Төп нөсхәләр | Күчермәләр |
| | | |
| | | |
| | | |
| | Барлыгы | Барлыгы |

«_______»_______________
(кабул ителү датасы)

Гариза бирүче (ышанычнамә буенча вәкил)

_______________________________________ ________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы белгече

_______________________________________ ________________________________
(фамилия, инициаллар) (имза)

Бөтен документлар 1 данәдә тапшырыла.

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 3 нче кушымта

ТР Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгында
җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында
гариза үтү
бите

Гариза бирүче ________________________________________________
Регистрация (керү) номеры _________________________

| N п/п | Министрлыкның структур бүлекчәләре | Алу датасы | Имза | Тапшыру датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Эш башкару һәм контроль бүлеге | | | | |
| 2. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге белгече | | | | |
| | Килештерүләр: | | | | |
| 3. | Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире | | | | |
| 4. | Җир ресурслары идарәсе башлыгы | | | | |
| 5. | Хокук идарәсе белгече | | | | |
| 6. | Хокук идарәсе башлыгы | | | | |
| 7. | Министрның беренче урынбасарының кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 8. | Министрның кабул итү бүлмәсе (документларны имзалау) | | | | |
| 9. | Эш башкару һәм контроль бүлеге ((документларны рәсмиләштерү һәм регистрация) | | | | |

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 4 нче кушымта

Җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту өчен нигезләр

Түбәндәге нигезләрнең берсе генә булса да, җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзүдән баш тарту турында карар кабул ителә:

1) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында гариза РФ ҖК $39^{28}$ статьясының 1 пунктында каралмаган очракларда бирелгән;

2) яңадан бүлергә тәкъдим ителгән җир кишәрлекләре затларның хокуклары белән бәйләнгән очракта, РФ ҖК $11^{2}$ статьясының 4 пунктында күрсәтелгән әлеге затларның язмача ризалыгы тапшырылмаган;

3) хосусый милектә булган җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка килгән җир кишәрлегендә, шулай ук, дәүләти һәм муниципаль милектә булган җирләрдә һәм (яки) җир кишәрлекләрендә дәүләти һәм муниципаль милектә булган, башка гражданнар яки юридик затлар милкендә булган биналар, корылмалар, төзелеп бетмәгән объектлар урнаштырылачак булса, сервитут шартларында корылмалар (шул исәптән төзелеп бетмәгән корылмалар), яки РФ ҖК $39^{36}$ статьясының 3 пунктында каралган һәм җир кишәрлеген рөхсәт ителгәнчә куллануга комачауламый торган объектлар чыгарылма булып тора;

4) территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлеген урнаштыру схемасында хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләти яки муниципаль милектә булып әйләнештән алынган яки әйләнеше чикләнгән җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү каралган, әлеге яңадан бүлү РФ ҖК 27 статьясының 5 пункты 7 подпунктында күрсәтелгән җир кишәрлекләре белән территорияне ызанлау проекты нигезендә башкарылу чыгарылма булып тора;

5) җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милек булган, шулай ук, дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗ өчен резервка куелган дәүләти һәм муниципаль милектә булган җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү юлы белән ясау каралган;

6) территорияне ызанлау проекты яки җир кишәрлеген урнаштыру схемасында хосусый милектәге җир кишәрлеген һәм дәүләти яки муниципаль милектә булып, РФ ҖК $39^{11}$статьясының 19 пункты нигезендә белдерү

урнаштырылып аукционга куелган җир кишәрлеген яңадан бүлү каралган, яисә бу җир кишәрлегенә мөнәсәбәтле аны бирү турында беренчел карар кабул ителгән, аның срогы чыкмаган;

7) җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милек булган, шулай ук, дәүләти һәм муниципаль ихтыяҗ өчен резервка куелган дәүләти һәм муниципаль милектә булган җирләрдә һәм (яки) җир кишәрлекләреннән ясау каралган һәм аларга мөнәсәбәтле җир кишәрлеген бирүне беренчел килештерү турында яки җир кишәрлеген бирү турында гариза бирелгән һәм беренчел килештерүдән яки бирүдән баш тарту турында карар кабул ителмәгән;

8) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү нәтиҗәсендә хосусый милек хокукы барлыкка киләчәк җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлекләре үлчәменең билгеләнгән максималь чикләреннән артып китәчәк;

9) җир кишәрлеген яки җир кишәрлекләрен хосусый милектә булган җир кишәрлеген, шулай ук, РФ ЖК $11^{9}$ статьясында каралган таләпләрне бозмыйча мөстәкыйль җир кишәрлеге ясап булган җирләрне яңадан бүлү юлы белән ясау каралган, җир кишәрлекләрен РФ ЖК $39^{28}$ статьясының 1 пунктының 1 һәм 4 подпунктларына туры китереп яңадан бүлү очраклары искәрмә булып тора;

10) хосусый милек булган җир кишәрлегенең чикләрен «Күчемсез милекнең дәүләт регистрациясе турында» федераль законга туры китереп ачыкларга кирәк;

11) җир кишәрлеген урнаштыру схемасын раслаудан баш тарту өчен РФ ЖК $11^{10}$ статьясының 16 пунктында каралган нигезләр бар;

12) җир кишәрлеген яңадан бүлү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасы ясала торган җир кишәрлекләренә куелган таләпләрне бозып эшләнгән яки территория планировкасының расланган проектына, җир ясау документациясенә, аеруча саклана торган территория турында нигезләмәгә туры килми;

13) ясалуы җир кишәрлеген урнаштыру схемасында каралган җир кишәрлеге территорияне ызанлау проектына мөнәсәбәтле территория чикләрендә урнашкан;

14) хосусый милек хокукы барлыкка килә торган җир кишәрлегенең мәйданы җир кишәрлеген урнаштыру схемасында яки территорияне ызанлау проектында күрсәтелгән җир кишәрлеге мәйданыннан ун процентка артып китә;

15) җир кишәрлеген яңадан бүлү турында гаризага беркетелгән җир кишәрлеген урнаштыру схемасы Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы белән килештерелмәгән, № 137-ФЗ Федераль законның $3^{5}$ статьясының 10 пунктында күрсәтелгән җирләрдән җир кишәрлекләре ясалу очраклары чыгарылма булып тора.

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына 5 нче кушымта

Киңәш ителгән форма

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрына
(кемнән)_____________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган:_____________________________________________________________________
______________________________________________________________________________

Дөрес мәгълүмат:______________________________________________________
______________________________________________________________________________

Җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында
«____»_________ 20______ел №________ килешүдә;
Җир кишәрлеге урнашу схемасын раслау турында
«____»_________ 20______ел №________ Министрлык карарында
техник хатаның төзәтелүен һәм тиешле үзгәрешләр кертелүен үтенәм.
Түбәндәге документларны беркетәм:
1.
2.
3.

Дәүләт хезмәте күрсәтелүе турында (күрсәтүдән баш тарту турында) мәгълүматны
______________________________________________________________________________
(язмача, электрон почта белән, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында Шәхси кабинетка)

_____________________________________________________алырга риза

________________ ___________________ ( _________________)
(дата) (имза) (фамилия, исеме, әтисенең исеме (булса)

М.П.(мөһер булганда)

Татарстан Республикасы милкендәге җирләрне һәм (яки) җир кишәрлекләрен һәм шәхси милектәге җир кишәрлекләрен яңадан бүлү турында килешү төзү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә**

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр<br>Әһлиуллин Фәнил Әнвәр улы | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары<br>Галиев Артур Ирек улы | 221-40-01 | mzio@tatar.ru |
| Җир ресурслары идарәсенең Дәүләт җирләреннән нәтиҗәле файдалану бүлеге мөдире<br>Миндубаева Гүзәл Эдуард кызы | 221-40-30 | Guzel.Mindubaeva@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире<br>Румянцева Гөлнур Нияз кызы | 221-40-81<br>221-40-83 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты, Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Агросәнәгать комплексы, җир мөнәсәбәтләре һәм куллану базары идарәсе башлыгы<br>Фәттерахманов Ленар Рифат улы | 264-76-89 | Lenar.Fatterahmanov@tatar.ru |